КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 август г.Казань № 884

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 15 июнь, 452 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 15 июнь, 452 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 26 март, 275 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендә мини-фермалар төзү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

9.4 пунктта:

«б» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

«в» пунктчасында «Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр йомгаклары буенча аны бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен бозу фактлары билгеләнгән очракта» сүзләрен төшереп калдырырга;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Министрлык субсидия алучыларның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра. Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

әлеге карар белән расланган Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сату өчен билгеләнгән һәм нәселле булган кысыр таналар һәм тана сыерлар сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

9.4 пунктта:

«б» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

«в» пунктчасында «Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр йомгаклары буенча аны бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен бозу фактлары билгеләнгән очракта» сүзләрен төшереп калдырырга;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Министрлык субсидия алучыларның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра. Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

әлеге карар белән расланган Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга өч яшьтән өлкәнрәк бияләр асрау чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Министрлык субсидия алучыларның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра. Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

әлеге карар белән расланган Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга савым сыерларын, ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән зуррак булган кәҗә бәтиләрен асрау чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Министрлык субсидия алучыларның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра. Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин